ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.03.2019 ел Баулы шәһәре №58

«2019-2023 елларда Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» муниципаль программасын раслау турында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендә кабул ителгән 209-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрләкне үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварында кабул ителгән 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. «2019-2023 елларда Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» муниципаль программасын расларга.

2. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «2016-2020 елларда Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү һәм аны үстерү» программасын раслау турында» 2016 елның 2 сентябрендә кабул ителгән 292нче номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче И.И. Гозәеров

ЭЧТӘЛЕК


| | | |
|---|---|---|
| I. | «2019-2023 елларда Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» муниципаль программасы паспорты……………….. | 3 |
| II. | Кереш өлеш………………………………………………………… | 5 |
| III. | Программаның гомуми өлеше……………………………………...... | 6 |
| 3.1. | «2019-2023 елларда Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» муниципаль программасы максаты һәм бурычлары....………………….............. | 6 |
| 3.2. | Агымдагы ситуацияне анализлау, Баулы муниципаль районында КУЭ үсеше проблемаларын бәяләү …………………………………… | 6 |
| 3.3. | Баулы муниципаль районы икътисадының төрле секторларында КУЭ үсеше …………………………………………………...................... | 10 |
| 3.4. | Баулы муниципаль районында куллану базарын үстерү ............... | 15 |
| 3.5. | Баулы муниципаль районы яшьләре арасында эшкуарлыкны үстерү.. | 16 |
| 3.6. | Баулы муниципаль районында сәнәгать мәйданчыкларын үстерү һәм резидентларны җәлеп итү .................………………………………….. | 17 |
| 3.7. | Баулы муниципаль районында халыкның үзмәшгульлеге өчен программа булдыру ………………………………………………… | 18 |
| IV. | Территориянең инвестицион җәлеп итүчәнлеген бәяләү, эшкуарлыкны үстерү юнәлешләре һәм конкрет чаралар исемлеге ……………………………………………….. | 19 |
| V. | КУЭ үсеше программасын ресурслар белән тәэмин итү …………… | 22 |
| VI. | Программаны тормышка ашырганда туарга мөмкин булган куркынычларны бәяләү һәм аларны җиңү ысуллары ………….. | 23 |
| VII. | Программаның планлаштырылган икътисадый нәтиҗәлелегә, программа белән идарә итү һәм аны гамәлгә ашыру барышын контрольдә тоту ........................................................................……... | 26 |
| VIII. | Йомгаклау………………………………………………………… | 28 |
| | 1нче КУШЫМТА………………………………………………… | 29 |

2нче КУШЫМТА

# I. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программа исеме | «2019-2023 елларда Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» муниципаль программасы (алга таба - Программа) |
| Программы төп эшләүче | Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм территориаль үсеш бүлеге |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | Программаның төп максаты Баулы муниципаль районы территориясендә гражданнарның мөстәкыйль эшкуарлык эшчәнлеген стимуллаштыручы һәм район өчен икътисадның өстенлекле тармакларында нәтиҗәле эшләүче кече һәм урта эшкуарлык субъектлары үсешен тәэмин итүче шартлар тудыру.<br>Программаның бурычлары:<br>- кече һәм урта эшкуарлык эшчәнлеген җайга салучы норматив-хокукый базаны камилләштерү;<br>- административ киртәләрне киметү һәм кече һәм урта эшмәкәрлекне тигез үстерү өчен уңай климат булдыру;<br>- кече һәм урта эшкуарлык субъектларына финанс һәм матди ярдәм күрсәтүне тәэмин итү;<br>- кече һәм урта эшмәкәрлекнең эшлекле мөмкинлекләрен киңәйтү;<br>- кече һәм урта эшмәкәрлек өлкәсе өчен квалификацияле кадрлар әзерләү;<br>- район өчен өстенлекле икътисад тармакларында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү;<br>- кече һәм урта эшкуарлык субъектларын мәгълүмати яктан тәэмин итүнең нәтиҗәлелеген арттыру;<br>- эшмәкәрлек эшчәнлеге мәсьәләләре, дәүләт ярдәме чаралары турында мәгълүматның һәркем өчен ачык булуын тәэмин итү. |
| Программаның максатчан индикаторлары һәм | Программа чараларының уңышлы үтәлеше 2023 елга түбәндәгеләргә ирешергә ярдәм итәчәк:<br>- кече һәм урта эшмәкәрлек өлкәсендә эшләүче район халкының гомуми саны 20,0%тан 20,6%ка кадәр артуы; |

| | |
|---|---|
| күрсәткечләре | - кече һәм урта эшмәкәрлек предприятиеләре саны 180нән 195 берәмлеккә кадәр арту;<br>- Баулы муниципаль районы бюджетының үз керемнәрендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан салым керемнәре өлеше 11,9%тан 13,5%ка кадәр арту;<br>- кече эшмәкәрлек субъектлары финанс әйләнеше 1,8 млрд. сумнан 2,3 млрд. сумга кадәр арту;<br>- тулаем территориаль күрсәткечтә кече һәм урта эшмәкәрлек өлеше үсеше 10,6%тан 11,0% ка кадәр арту;<br>- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары булган заказчыларның сатып алуларда катнашу өлеше 45,0%ка кадәр арту. |
| Программаны тормышка ашыру этаплары һәм сроклары | 2019 – 2023 еллар |
| Программаны тормышка ашыручылар | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары, Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты бүлекләре һәм структур бүлекчәләре, «Баулы шәһәре мәшгульлек үзәге» ДКУ, «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ, Баулы районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе |
| Финанслау күләме һәм чыганаклары | Гамәлдәге законнар белән тыелмаган федераль, республика, җирле бюджет акчалары, башка чыганаклар |
| Программаның үтәлешен контрольдә тоту | Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм территориаль үсеш бүлеге программаны үтәү буенча чараларны оештыра, координацияли һәм контрольдә тота |
| Программаны тормышка ашыруның төп нәтиҗәләре | - кече һәм урта эшмәкәрлекнең тотрыклы үсеше;<br>- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары саны арту;<br>- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан булдырылган эш урыннары арту;<br>- Баулы муниципаль районында эшләүчеләрнең гомуми санында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары хезмәткәрләре өлеше арту;<br>- җирле бюджетның үз керемнәрендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан салым керемнәре өлеше арту. |

## II. Кереш өлеш

Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү базар системасының аерылгысыз элементы булып тора, ул Россиядә икътисадый реформалары максатларына – халыкның тормыш дәрәҗәсен югары һәм сыйфатлы итәрлек конкурентлы икътисад булдыруга туры килә.

Кече бизнес елдан-ел Баулы муниципаль районы икътисадында зуррак роль уйный, җитештерү белән бәйле һәм җитештерү белән бәйле булмаган эшчәнлекне оештыруның нәтиҗәле формаларының берсе булып тора, куллану базарын сыйфатлы товарлар һәм җирле производство хезмәтләре белән баету, халыкның тормыш дәрәҗәсен һәм мәшгульлеген арттыру проблемаларын хәл итү, бюджет системасына салым кертемнәрен арттыру кебек районның икътисади юнәлешләрен үстерүгә йогынты ясый.

Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшмәкәрлекне үстерү юнәлешендәге эшчәнлекләрен «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15нче статьясында һәм «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендә кабул ителгән 209-ФЗ номерлы Федераль законның 11нче статьясында күрсәтелгән вәкаләтләр кысаларында алып баралар.

Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының эшчәнлеге характеры һәм масштабы Баулы муниципаль районында эшлекле һәм икътисадый климатның мөһим индикаторлары булып тора. Кече һәм урта бизнес өлкәсендә көндәшлекне үстерү, өстәмә эш урыннарын арттыру, салым базасын киңәйтү, тулай эчке продуктны арттыру потенциалы салынган.

Программаның төп бурычларыннан берсе – халык арасында эшкуарлык активлыгы үсешенә, бизнесның тармак структурасын үзгәртүгә максималь йогынты ясарлык уңай шартлар тудыру. Җитештерү секторына кече һәм урта бизнес вәкилләрен мөмкин кадәр күбрәк җәлеп итү өчен кулдан килгәннең барысын да эшләргә кирәк.

## III. Программаның гомуми өлеше

## 3.1. «2019-2023 елларда Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» муниципаль программасы максаты һәм бурычлары

Программаның төп максаты Баулы муниципаль районы территориясендә гражданнарның мөстәкыйль эшкуарлык эшчәнлеген стимуллаштыручы һәм район өчен икътисадның өстенлекле тармакларында нәтиҗәле эшләүче кече һәм урта эшкуарлык субъектларының үсешен тәэмин итүче шартлар тудыру.

Программаның бурычлары:

кече һәм урта эшкуарлык субъектларына финанс һәм мөлкәти ярдәм күрсәтүне тәэмин итү;

район өчен өстенлекле икътисад тармакларында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү;

кече һәм урта эшмәкәрлекнең эшлекле мөмкинлекләрен киңәйтү;

кече һәм урта эшкуарлык эшчәнлеген җайга сала торган норматив-хокукый базаны камилләштерү;

эшкуарлык эшчәнлеге мәсьәләләре, дәүләт ярдәме чаралары турында мәгълүматның һәркем өчен ачык булуын тәэмин итү;

кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын мәгълүмати тәэмин итүнең нәтиҗәлелеген арттыру;

кече һәм урта эшмәкәрлек өлкәсе өчен квалификацияле кадрлар әзерләү;

административ киртәләрне киметү һәм кече һәм урта эшмәкәрлекне тигез үстерү өчен уңай климат булдыру.

## 3.2. Агымдагы ситуацияне анализлау, Баулы муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлык үсеше проблемаларын бәяләү

Кече бизнес муниципаль районның социаль-икътисадый үсешенә сизелерлек өлеш кертә. Кече һәм урта бизнес вәкилләренең социаль җаваплылыгы артты. Үз эшләрен оештыру, кулланучыларга хезмәт күрсәтү дәрәҗәсе заманча һәм цивилизациялерәк була бара.

Баулы муниципаль районы икътисады үз эченә нефть сәнәгатен, авыл хуҗалыгын, төзелеш, транспорт хезмәтләре күрсәтүне, ваклап сату сәүдәсен һ. б. ала.

Тулай территориаль продуктта кече бизнес субъектлары өлеше 10,6 % тәшкил итә. Кече бизнес субъектларының өлеше түбән булу муниципаль район икътисадының нефть-газ чыгару тармагына бәйлелеге белән бәйле. 2018 елда

эчке территораль продуктта нефть тармагы өлеше 70,0 % тәшкил итте.

2018 елның 1 октябренә Баулы муниципаль районында 2 урта һәм 181 кече эшмәкәрлек субъекты, 650 шәхси эшмәкәр үз эшчәнлекләрен алып барды. Авыл хуҗалыгы тармагында 14 хуҗалык, 44 кече крестьян-фермер хуҗалыгы, 8 763 шәхси хуҗалык мәшгуль. Алар барысы да, заманча технологияләр кертеп, беркетелгән җирләрдә уңышлы эшлиләр.

Кече бизнес өлкәсендә рәсми рәвештә 1757 кеше эшли, бу районның барлык предприятиеләре хезмәткәрләренең гомуми санының 20,3% ын тәшкил итә.

Кече предприятиеләрнең әйләнеше 2018 елның 9 аенда 1 млрд.253 млн. сум тәшкил итте, 2017 елның шул ук чорына карата үсеш 103,1% тәшкил итте.

Кече бизнес өлкәсендә эшләүчеләрнең уртача айлык хезмәт хакы 2018 елның 9 аенда 16 352,10 сум тәшкил итте, узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда үсеш 108,4%.

Эшмәкәрлек икътисадтагы конкурентлы тонусны сакларга ярдәм итә, базар башлангычларында оештырылган иҗтимагый корылышка социаль терәк булып тора һәм җәмгыятьнең социаль катламын формалаштыра.

Кече бизнесның тармак структурасы, андагы эш белән тәэмин итү һәм продукцияне (хезмәт күрсәтүләрдән) реализацияләүдән кергән табыш структурасы эшмәкәрлек күбесенчә сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү өлкәсендә үсеш алуын күрсәтә. Әлеге хезмәт күрсәтү өлкәләре 24,0% тәшкил итә, аның 20,0% – төзелешкә, 10,0% – эшкәртү производствосына, 7,0% – авыл хуҗалыгына, 6,0% – транспорт хезмәтләренә туры килә.

Баулы шәһәрендә Федераль сәүдә челтәрләренең актив үсешенә карамастан, соңгы елларда эшмәкәрләр эшчәнлегенең иң киң таралган төре булып, элеккечә, ваклап сату сәүдәсе кала бирә. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, соңгы 4 елда шәһәр һәм районның сәүдә нокталарында сатып алучыларга тәкъдим ителгән товарларның күләме һәм ассортименты шактый киңәйтелде. Эшмәкәрлек структурасы эшчәнлекнең түбәндәге төрләреннән формалаша:

- күпләп-ваклап сату, автотранспорт чараларын һәм мотоциклларны ремонтлау – 44,3%;
- авыл һәм урман хуҗалыгы, ау, балыкчылык һәм балык үрчетү – 15%;
- транспортлау һәм саклау – 8%;
- эшкәртү производствосы – 4,6%;

- төзелеш – 4,2%;

– профессиональ, фәнни, техник эшчәнлек – 4%.

Эшмәкәрлек структураларының матди-техник базасы ныгуын дәвам итә, аларның эшчәнлеге формалары һәм ысуллары камилләштерелә.

Соңгы елларда районда халыкка хезмәт күрсәтүче кече бизнес предприятиеләре дә актив үсеш ала. Беренче чиратта, ял оештыру. Мәсәлән, балалар күңел ачу үзәкләре, банкет заллары, бәйрәмнәр оештыру һәм башкалар. 2019 ел башына районда балалар иҗатын үстерү буенча 5 учреждение, 21 кафе эшли («Полет» кафесы ачылды) иде.

Шулай ук халыкта сәламәтлек һәм матурлык хезмәтләренә ихтыяҗ зур. Бу сәламәтлек үзәкләре, чәчтарашханәләр, матурлык салоннары кебек проектларда чагылыш таба. 2018 елның 9 аенда районда шундый 9 бина ачылды.

2015-2018 еллардагы кече һәм урта эшкуарлыкның икътисадый күрсәткечләренә анализ 1нче таблицада китерелгән.

1нче таблица

| № п/п | Күрсәткеч исеме | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел Бәя |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Икътисади актив кече предприятиеләр саны, бер. | 221 | 195 | 190 | 180 |
| 2. | Теркәлгән шәхси эшмәкәрләр саны, бер. | 630 | 642 | 643 | 650 |
| 3. | Уртача айлык хезмәт хакы, сум. | 19064,8 | 15026,8 | 15056,3 | 16300,0 |
| 4. | Кече предприятиеләр әйләнеше, млн. сум. | 1573,3 | 1726,1 | 1832,8 | 1895,1 |
| 5. | Кече предприятиеләрдә хезмәткәрләрнең уртача саны, бер. | 1006 | 981 | 992 | 980 |
| 6. | Кече һәм урта эшкуарлык өлкәсендә эш белән тәэмин ителгән халык өлеше (районның барлык предприятиеләре хезмәткәрләренең уртача санына карата, %) | 18,2 | 18,9 | 19,8 | 20,0 |
| 7. | Тулаем территориаль продуктта кече һәм урта бизнес өлеше, % | 10,6 | 10,6 | 10,6 | 10,6 |
| 8. | Җирле бюджетка кече эшмәкәрлек субъектларыннан салым һәм салым булмаган түләүләр керү, млн. сум. | 40,8 | 42,05 | 44,4 | 45,7 |
| 9. | Җирле бюджет кертемнәрнең гомуми | 9,2 | 9,5 | 10,8 | 11,9 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | күләмендә КУЭдан салымнар һәм түләүләр өлеше, % | | | | |
| 10. | КУЭ субъектлары катнашкан сатып алулар өлеше, % | 21 | 39 | 37 | 61,5 |

Анализ (1нче таблица) кече предприятиеләр саны кимегәнен күрсәтә Бу «бер көнлек» предприятиеләрне бетерүгә бәйле. Акрын булса да, шәхси эшмәкәрләр саны арта бара. Район икътисадына җирле бюджетка салым һәм салым булмаган түләүләр зур өлеш кертә, әлеге күрсәткеч 2015 елдан 2018 елга 40,8 млн. сумнан 45,7 сумга кадәр артты.

Шулай ук «Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары катнашкан сатып алулар өлеше» күрчәткече уңай динамикага ия. 2018 елда әлеге күрсәткеч 61,5% тәшкил иткән.

Баулы муниципаль районы территориясендә җирле үзидарә органнарының һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларының үзара хезмәттәшлеге нәтиҗәлелеген арттыру, районның социаль-икътисадый үсешенең төп юнәлешләре буенча тәкъдимнәр эшләү һәм уртак эшчәнлекне координацияләү максатларында Баулы муниципаль районының кече һәм урта эшмәкәрлеген үстерү буенча Координация советы төзелде.

Баулы муниципаль районының кече эшмәкәрлек субъектлары арасында үткәрелгән сораштыру нигезендә кече бизнес вәкилләре алдында барлыкка килгән түбәндәге төп проблемаларны аерып күрсәтергә мөмкин:

җайга салу һәм ярдәм күрсәтүнең норматив-хокукый базасы камил булмавы;

финанслар һәм кредитлар белән ярдәм итүнең һәм матди ресурслар белән тәэмин итүнең нәтиҗәле механизмнары булмау;

салым салу системасының камил булмавы;

яңа эш башлаучы эшмәкәрләргә комплексылы ярдәм күрсәтү структурасы булмавы;

әйләнеш капиталын тулыландыру өчен банктан кредит алып булмавы (кыйммәт булу һәм банк өчен җитәрлек булган залог юклыгы аркасында). Кече эшкуарлыкка финанс-кредит ярдәме күрсәтү проблемалары кече предприятиеләрнең финанс яктан тотрыклылыгы һәм залог калдыру мөмкинлеге түбән булу, кече эшкуарлык субъектларының традицион финанс инструментларын куллану мөмкинлекләре чикләнгәнлеге һәм кече эшкуарлыкка ярдәм итүнең нәтиҗәле финанс механизмнары булмау аркасында

килеп чыга. Шуңа күрә кече предприятиеләрнең банк кредиты алу мөмкинлеге чикләнгән;

кече һәм урта эшкуарлык җитәкчеләренең һәм шәхси эшкуарларның хокукый, финанс, салым законнары мәсьәләләрендә әзерлеге җитәрлек булмавы;

салым, таможня, пенсия, финанс, җир, табигать саклауа кагылышлы һәм башка Россия законнарының еш үзгәреп торуы;

табигый монополияләр хезмәтләренә тарифлар һәм бәяләр күтәрелү;

финанс чаралары җитмәү сәбәпле, җирле үзидарә органнары тарафыннан финанс ярдәме җитәрлек дәрәҗәдә булмавы.

### 3.3. Баулы муниципаль районы икътисадының төрле секторларында кече һәм урта эшмәкәрлек үсеше

Муниципаль район территориясендә кече бизнес икътисадының түбәндәге секторлары актив үсә:

- ваклап сату, көнкүреш хезмәтләре;
- төзелеш;
- авыл хуҗалыгы.

Кече бизнесның актив үсеп килүче предприятиеләре арасында түбәндәге предприятиеләрне аерып алырга мөмкин:

1. Биктерра «ҖЧҖ»

Предприятие 20 төрле брусчатка, мунча өчен агач эшләнмәләре, коеп ясалган әйберләр (капкалар, беседкалар), профнастил, сайдинг, керамзит-бетон блоклар җитештерә. Бүгенге көндә хезмәткәрләр саны 47 кеше тәшкил итә.

2. Садыков Р. А. КФХ

Сөт заводының җитештерү куәте айга 167 тонна тәшкил итә. Предприятие сөт продукциясенең 20 төрен җитештерә. Төп кулланучылар – Баулы шәһәрләре һәм Татарстан Республикасы һәм Башкортостан Республикасының якындагы шәһәрләре һәм районнары азык-төлек ваклап сату челтәрләре, балалар бакчалары, мәктәпләр, ашханәләре.

Заводта 40 эш урыны булдырылган. 2019 ел башында өстәмә рәвештә бер сәгатькә 3000 пластик шешә җитештерү һәм аны сөт продукциясе белән тутыру буенча яңа цех ачылды, шул ук вакытта өстәмә 6 эш урыны булдырылды.

3. <u>ООО «Башак»</u>

Компания бөртекле һәм үсемлек культураларыннан он җитештерә. Хезмәткәрләр саны 8 кеше тәшкил итә. Җитештерелгән продукция нигездә Татарстан Республикасының һәм Башкортостан Республикасының күрше районнарында сатыла.

4. <u>«Баулы икмәк заводы» ҖЧҖ</u>

Икмәк-күмәч эшләнмәләре ассортименты 40 төрдән артык тәшкил итә, ассортиментны 60ка кадәр арттыру планлаштырыла. 60 эш урыны булдырылган. Печенье, прәннек һәм зефир җитештерү җиһазлары урнаштырылды. Элек бу төр продукция районга күрше өлкәләрдән кертелә иде. Туңдырылган ярымфабрикатлар җитештерү (20дән артык төр) цехы ачылды. Продукция Баулы муниципаль районының сәүдә объектларына һәм «Пятерочка», «Эссен», «Магнит», «Изобилие» кибетләренә, шулай ук Татарстан Республикасының һәм Башкортостан Республикасының күрше районнарына җибәрелә.

Авыл хуҗалыгы терлекчелеккә юнәлдерелгән – сөт-ит терлекчелеге, сарык үрчетү, умартачылык; сабан ашлыгы, көзге арыш, арпа, карабодай, борчак үстерелә. Районныж аеруча эре авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре: «Берлек» ҖЧҖ, «Кызылъяр» ҖЧҖ, «Николашкино» ҖЧҖ, «Исламгалиев» КФХ, «Миңнуллин» КФХ.

Агросәнәгать паркы җитештерелгән продукцияне сатуда зур ярдәм булды. Агросәнәгать паркы территориясендә атна саен авыл хуҗалыгы ярминкәләре оештырыла.

Шулай ук район территориясендә түбәндәге яңа проектлар актив үсеш ала:

1) «Баулы муниципаль районының Кызылъяр авыл җирлеге территориясендә җиләк-җимеш һәм җиләк культуралары үстерү» («Юнысов С. Р. » КФХ). «Юнысов С. Р.» КФХ – яңа эш башлаучы фермер, 2018 елда район территориясендә җиләк-җимеш һәм җиләк культуралары үстерү буенча үз эшчәнлеген башлап җибәрде. Әлеге проект Баулы муниципаль районы халкын сыйфатлы һәм һәркем алырлык продукция белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк. 5 яңа эш урыны булдырылган. Кертелгән инвестицияләр күләме 1,5 млн сум тәшкил итә;

2) «Тимурбаева Р. М. КФХ гаилә фермасы» (Баулы муниципаль районының Александровка авылы). «Тимербаева Р. М.» КФХ ун елдан артык район территориясендә эре мөгезле терлек үрчетә. Өстәмә 3 яңа эш урыны булдырылган. Әлеге проект Баулы муниципаль районының Александровка авыл җирлеге территориясендә яңа гаилә терлекчелек фермасы төзергә һәм савым сыерлары санын 50 башка арттырырга мөмкинлек бирде;

3) Баулы муниципаль районының Татар Кандыз авыл җирлеге территориясендә «Исламгалиевлар» КФХ 1500 баш мөгезле эре терлек симертү фермасы төзү планлаштыра. Ферма төзү эре мөгезле терлекләр санын арттырырга һәм 20 эш урыны булдырырга мөмкинлек бирәчәк. Әлеге проектны гамәлгә ашыру 2019 елга планлаштырылган. Проект Баулы муниципаль районының социаль-икътисади үсеше өчен кирәк.

4) «Төзелеш материаллары җитештерү» («Рус» ҖЧҖ, Геворгян Э. Р.). 2018 елда төзелеш материаллары: поребриклар, бордюралар, брусчатка, керамзит блоклар, профнастил, черепица, гипсокартон өчен профильләр җитештерү линиясе ачылды. Бүгенге көндә асфальт-бетон заводын монтажлау эше бара, аны 2019 елның 2 кварталында эшләтеп җибәрү планлаштырыла. Хезмәткәрләр саны 45 кеше тәшкил итә.

5) 2019 елның 2нче кварталында «Александровка спирт заводы» ҖЧҖ предприятиесе базасында этилацетатның сынау партиясен җитештерү буенча яңа җиһазлар эшләтеп җибәрү планлаштырыла. «Александровка спирт заводы» ҖЧҖ генераль директоры Гафуров Айдар Анурбекович Баулы муниципаль районында этилацетат җитештерү (этилацетат, коры азык чүпрәсен, азык-төлек углекислотасы) заводын төзү инициативасы белән чыкты. Продукцияне Татарстан Республикасы предприятиеләренә (ЕвроСэФ, Татарстан ДИО, Казан аз тоннажлы химия заводы, «Хитон» ААҖ) һәм Башкортостан Республикасы предприятиеләренә («КОЛОРГРАД» ҖЧҖ, «УРАЛРЕГИОН» ҖЧҖ, «Весна» ҖЧҖ, «Бирская лакокрасочная компания» ҖЧҖ, «Уральские краски» ҖЧҖ) тәкъдим итү күздә тотыла. Хәзерге вакытта предприятиедә 300 м3 мәйданлы уксус кислотасы складын төзү һәм 22 махсус насос урнаштыру эшләре бара, шулай ук проект-смета документациясенә үзгәрешләр кертелә.

6) Районга туристларны җәлеп итү өчен туризм өлкәсендә дә бизнес үсә. Табигатьтә актив ял итәргә һәм балык тотырга яратучылар районның балык үрчетү хуҗалыкларына бик теләп киләләр. Баулы районында бүгенге көндә

шундый 3 хуҗалык бар. «Дымка” балык хуҗалыгы (ИП Сәлимов Р. С.) иң эре балык үрчетү хуҗалыгы булып тора. Нигездә, хуҗалык карп үрчетү һәм күпләп сату белән шөгыльләнә. Балык тотарга яратучылар биредә түләүле нигездә тота ала. Балык тотарга яратучылар Баулы районыннан гына түгел, якын-тирә төбәкләрдән дә киләләр.

«Экият» балыкчылык хуҗалыгы (ИП Нуриева Г.И.) һәм «Яхшы балык тоту» (ИП Фәттахов Р. З.). Бу хуҗалыклар ял итүне балыкчылык белән берләштерүгә юнәлдерелгән. «Әкият» балык үрчетү хуҗалыгы территориясендә палаткалар шәһәрчегендә тулы кыйммәтле ял тәкъдим ителә. Транспорт өчен махсус стоянка бар. Ял итүчеләр өчен таулар, урман, елга, күл, пляж волейболы, өстәл теннисы, мини футбол, җирле флора һәм фауна белән фотосессия, балык тоту (сентябрь, октябрь) тәкъдим ителә. Территория төзекләндерелгән, шаян күрсәткечләр, табличкалар бар, эчә торган су, поход мунчасы бар. Беседкалар һәм учаклар ягу өчен яхшы урыннар бар. «Әкият» балык хуҗалыгы яшьләр һәм корпоратив клиентлар арасында бик популяр. Сезонлы – майдан октябрьгә кадәр эшли. Балык хуҗалыгына кадәр яхшы грунт юлы бар.

«Яхшы балык тоту» хуҗалыгы үз туристларын төзекләндерелгән өйләрдә кабул итә. Территориясендә шундый 5 йорт бар, электр кертелгән, җылытыла Йорт янындагы территориядә беседка, мангал, газ плитәсе һәм умывальниклар, бәдрәф һәм буа аркылы күперләр урнаштырылган. Балык хуҗалыгына юл, нигездә, асфальт буенча, территориягә керү урынында грунт юл.

7) 2018 елның августында Баулы муниципаль районының Кызылъяр авыл җирлегенең Уба авылы янында (Татарстан һәм Башкортстан чигендә, М-5 трассасы буенда) CRG-200 урта магистраль самолетында 29 кешелек «Полёт» кафесы ачылды.  2019 елда шул ук территориядә «Поляна» рестораны ачу планлаштырыла. Әлеге бинаны шәхси эшмәкәрләр Аркадий һәм Араик Манукян ачты. Балык тотарга яратучылар өчен дә карьерларда сезон вакытында түләүле балык тоту оештырыла. Беседкалар һәм учак ягу урыннары бар. Кертелгән инвестицияләр күләме 2 млн. сум.

8) Районда туризмны үстерү өлкәсендә шулай ук балалар ялын, туристик походларны һәм палаткалы лагерьларны оештыру белән шөгыльләнүче «Радуга» ЦООТ ҖЧҖ актив эш алып бара.

Районда юл буе сервисын үстерү мәсьәләсе актуаль булып кала. Моны бары кече эшкуарлык субъектлары катнашында гына башкару мөмкин.

### 3.4. Баулы муниципаль районында куллану базарын үстерү

Эшмәкәрлек эшчәнлеге бүген сәүдә, сәнәгать производствосында, көнкүреш хезмәтләре күрсәтүдә, авыл хуҗалыгы производствосында үсеш ала. Федераль сәүдә челтәрләре актив үсүгә карамастан («Магнит», «Магнит у Дома», «Пятерочка», «Кызыл һәм Ак», «Изобилие»), соңгы елларда эшмәкәрләр эшчәнлегенең киң таралган төре булып, элеккечә, ваклап сату кала бирә. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, соңгы дүрт елда районның сәүдә нокталарында сатып алучыларга тәкъдим ителгән товарларның күләме һәм ассортименты шактый артты һәм киңәйде. Алда әйтелгәнчә, шәхси эшмәкәрләр структурасында эшмәкәрләрнең 44%ы ваклап сату, автотранспорт чараларын һәм көнкүреш әйберләрен ремонтлау өлкәсендә шөгыльләнә.

2018 елда кече бизнес өлкәсендә 140 эш урыны булдырылган. Кече бизнес район халкы өчен шактый эш урыннары булдырып кына калмый, район икътисадына зур өлеш тә кертә.

2018 елның 9 аенда ваклап сату әйләнеше 3 140,2 млн. сумнан артык тәшкил итте, үсеш темпы – 104,5%.

2018 елның 9 аенда түләүле хезмәтләрне гамәлгә ашыру күләме 544,8 млн. сум тәшкил итте, әлеге күрсәткеч узган ел белән чагыштырганда 4% ка кимеде.

2018 елның 9 аенда сәүдә хезмәткәрләренең уртача айлык хезмәт хакы 22190 сум тәшкил итте, узган ел белән чагыштырганда үсеш – 104,3%.

2015-2018 елларда куллану базарында кече бизнесның үсеш динамикасы 2нче таблицада китерелгән.

2нче таблица

| № п/п | Күрсәткеч исеме | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел бәя |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Ваклап сату, автотранспорт чараларын һәм мотоциклларны, көнкүреш әйберләрен ремонтлау белән шөгыльләнүче кече предприятиеләр саны, бер. | 35 | 46 | 39 | 44 |
| 2. | Ваклап сату, автотранспорт чараларын һәм мотоциклларны ремонтлау белән шөгыльләнүче шәхси эшмәкәрләр саны | 313 | 312 | 296 | 285 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | бер. | | | | |
| 3. | Ваклап сату әйләнеше, млн. сум. | 3801,6 | 4002,5 | 4121,0 | 4306,4 |
| 4. | Җан башына ваклап сату әйләнеше, мең сум. | 106,9 | 113,0 | 116,9 | 123,8 |
| 5. | Түләүле хезмәтләрне гамәлгә ашыру күләме, млн. сум. | 832,1 | 850,5 | 726,8 | 727,0 |
| 6. | Җан башына түләүле хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыру күләме, мең сум. | 23,4 | 24,0 | 20,6 | 20,8 |

Кече һәм урта бизнес секторындагы уңай динамикага карамастан, алга таба үсеш өчен чаралар кабул итүнең актуальлеге ачык күренә. Бу икътисади актив урта сыйныф формалаштыру юлы белән халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, икътисади үсеш темпларын арттыру зарурлыгына бәйле.

### 3.5. Баулы муниципаль районы яшьләре арасында эшкуарлыкны үстерү

Яшьләрне районның һәм шәһәрнең социаль-икътисадый үсешенә җәлеп итү, яшьләр эшкуарлыгына ярдәм итү максатларында Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты «2016-2020 елларда Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының яшьләр эшкуарлыгына ярдәм» муниципаль программасын кабул итте.

Программаның бурычлары:

- яшьләрне эшмәкәрлек эшчәнлеге өлкәсендә мәгълүмати тәэмин итү системасын үстерү;
- эшкуарлык эшчәнлегенең уңай имиджын һәм абруен формалаштыру;
- эшлекле яшьләр өчен белем бирү программаларын эшләү һәм гамәлгә кертү;
- яшь эшкуарларга кураторлык итү һәм яшьләр эшкуарлыгының бизнес-проектларын алга этәрү.

Социаль активлыкны үстерү өчен яшьләр һәм мәктәп укучыларына балчыктан һәм гипстан сыннар ясау буенча мастер-класслар, консультацияләр, яшь эшмәкәрләр һәм югары сыйныф укучыларының идеяләрен бәяләү, апробацияләү үткәрелә.

Яшьләрне эшмәкәрлек эшчәнлегенә тарту максатында районда «Эшкуарлык фабрикасы» һәм «Бизнес десант» кебек белем бирү проектлары даими үткәрелә, анда югары сыйныфлар һәм аграр көллият укучылары катнаша. Шулай ук алар өчен бизнес вәкилләре катнашында очрашулар, түгәрәк өстәлләр уздырыла.

Эшмәкәрлек эшчәнлеген стимуллаштыру һәм инициативага ярдәм итү максатында ел саен «Елның иң яхшы эшкуары» конкурсы уздырыла, анда районның иң яхшы эшкуарлары 11 номинация буенча бүләкләнә, шул исәптән «Иң уңышлы эшләүче яшь эшкуар» номинациясе буенча да. Шулай ук районның яшь эшкуарлары «Россиянең яшь эшкуары» региональ конкурсында катнаша. 2018 елда төбәк конкурсында Баулы районыннан 4 эшмәкәр катнашты. Баулы шәһәренең яшь эшкуары Артак Микаелян бу конкурста «Авыл хуҗалыгы эшмәкәрлеге» номинациясендә дипломант булды.

## 3.6. Баулы муниципаль районында сәнәгать мәйданчыкларын үстерү һәм резидентларны җәлеп итү

Икътисадның реаль секторы үсешен тәэмин итү максатларында, бизнес алып бару өчен уңайлы шартлар тудыручы муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыкларын актив үстерү планлаштырыла. Бүгенге көндә районда 2015 елда файдалануга тапшырылган «Агропарк» ҖЧҖ (ИП Ягудин И. А.) Агросәнәгать паркы бар. Территориянең гомуми мәйданы 40 000,00 кв. м., бинаның мәйданы 1 500 кв. м. тәшкил итә. Агропаркта алты резидент – Розиков С. А. ШЭ, Миңнеханова А. К. ШЭ, Мөхетдинов И. Р. ШЭ, Ягудина Ф. С. ШЭ, Мамаев А. Н. ШЭ, Денисламов И. М. ШЭ эшли, аларда 14 хезмәткәр мәшгуль.

Бораулау эшләре идарәсенең элеккеге эретмә-бетон узелы базасында «СпецПромПрогресс» ҖЧҖнең яңа предприятиесе булдырылган. Предприятие эшчәнлегенең төп юнәлеше-нефть-газ җиһазлары җитештерү һәм сервисы, нефть һәм газ скважиналарын капиталь һәм агымдагы ремонтлау өчен яңа һәм стандарт булмаган төр җиһазлар эшләү.

Элеккеге «Баулынагрохимсервис» ААҖ базасы территориясендә 4 яңа предприятие төзелде: «Биктерра» ҖЧҖ, «Башак» ҖЧҖ, Садыков Р. А. КФХ сөт заводы һәм «Автоцентр» кибете.

Элеккеге «Баулы ПАТП» ААҖ территориясендә «СК Арт» ҖЧҖ предприятиесе юл һәм тротуар бордюрлары, керамзит һәм доломит блоклары җитештерә. Цехта 7 кеше эшли.

Баулы муниципаль районында бар:

- 1,5 га мәйданлы муниципаль җир, аларда 1772 кв. м мәйданлы 18 буш күчемсез милек объекты урнашкан;

- «Татнефть-Актив» ҖЧҖнең буш торучы җитештерү базасы (гомуми мәйданы 7 500 кв.м., әзер инженерлык коммуникацияләре (газ, ут, су), җир участокларының гомуми мәйданы 11,6 га булган 16 бина). Кызганычка каршы, әлеге мәйданнарны эшкә кертү бик катлаулы.

### 3.7. Баулы муниципаль районында халыкның үзмәшгульлеге өчен программа булдыру

Финанс хәле катлаулы булган яки акчасы яисә банктан кредит алу мөмкинлеге булмаган килеш үз эшен оештырырга теләгән һәркем халыкның үзмәшгульлегенә ярдәм итү программасыннан файдалана ала. Әлеге программада 18 яшькә җиткән һәм үз эшен оештырырга теләгән, рәсми рәвештә эшсез дип исәпләнгән Россия Федерациясе гражданнары катнаша ала. Ул Баулы шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәгендә консультация, иң мөһиме – эшмәкәрлек эшчәнлеген оештыруга финанс ярдәм алырга мөмкин, аның күләме бүгенге көндә 117 600 сум тәшкил итә.

2018 елда үз эшен ачуга Баулы шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәгендә исәптә торучы 11 кеше гомуми суммасы 1 млн. 287 мең сумлык субсидия алды.

2019 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы территориясендә «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын билгеләү буенча эксперимент үткәрелә. Бу үзмәшгуль гражданнарның керемнәрен легальләштерү өчен эшләнә, чөнки асылда алар “күләгәдәге бизнес” белән әөгыльләнә һәм бернинди салым түләми. Районда махсус салым режимын куллану буенча сынау проектын тормышка ашыру өчен «Юл картасы» эшләнде. «Юл картасы» нигезендә өйдә эш алып баручы гражданнар белән очрашулар, салым хезмәте, Пенсия фонды, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге вәкилләре катнашында консультатив ярдәм рәвешендә киңәшмәләр үткәрелә.

## IV. Территориянең инвестицион җәлеп итүчәнлеген бәяләү, эшкуарлыкны үстерү юнәлешләре һәм конкрет чаралар исемлеге

Баулы муниципаль районының инвестицияләр кертү өчен отышлы район дигән имиджы бар.

